Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре

“Алсу” балалар бакчасы мәктәпкәчә муниципаль бюджет белем учреждениясе

# “*Кәрзиндә чәчәкләр*” ясау буенча мастер-класс

(6-7 яшьлек балаларның әниләре белән)

Тәрбияче: Асылмарданова Ф.Ф.

27 ноябрь 2014ел.

МАСТЕР- КЛАСС.

**Тема: “ Кәрзиндә чәчәкләр” ясау. (1слайд)**

**Максат:** 1. Әниләрне лենталардан кәрзиндә чәчәкләр ясарга өйрәтү. **(2слайд)**

2.Матурлыкка мәхәбәт тәрбияләү.

3.Үз кулларың белән ясалган әйбернең кадерен белү.

4.Кызыксынучанлык, фикерләү сәләтен, танып белү эшчәнлеген үстерү.

5.Хезмәткә хөрмәт тәрбияләү.

**Кирәкле материаллар**: сабын, инә, лента, тимер чыбык, кайчы**. (3слайд)**

Эшчәнлекнең барышы.

1.Оештыру.

2.Төп өлеш. “Кәрзиндә чәчәкләр” ясау.

Әниләр, бүген мин сезгә кәрзиндә чәчәкләр ясау буенча мастер-класс күрсәтәм. Моның өчен кирәкле материалларны алдан әзерлибез: сабын, кайчы, тимер чыбык, төрле төстәге ленталар, инәләр.

Кәрзиндә чәчәкләр ясау өчен 1 сабын, 88 инә (сабынның зурлыгына карап), чәчәк ясау өчен 30 см.лента(20 шт), кәрзинне әйләндереп алу өчен 2.5см. лента, кәрзиннең аскы өлешен өйләндереп алырга 1м лента, яфракка 10см. лента кирәк, тимер чыбык 17см., аны лента белән әйләндереп алу өчен 1м. лента кирәк. **(4слайд)**

**Кәрзинне ясау өчен**

-сабын тирәли инәләрне кадап чыгабыз.

-Өске өлешкә тигез ара калдырып инәләрне кадап чыгабыз. (**5слайд)**

-шулай ук аскы өлешкә тигез ара калдырып инәләрне кадап чыгабыз.(өстәге инәләр белән астагы инәләрнең аралары тигез булырга).(**6 слайд**)

**Ленталар белән эшлибез**

- лентаны әз генә бөкләп читтәге инә белән сабынга беркетәбез**. (7слайд)**

-лентаны инәләр арасыннан әйләндерәбез.

-кәрзиннең аскы өлеше тирәли лентаны әйләндереп алабыз (2 рәт). **(8слайд)**

**Кәрзиннең тоткасын ясау**

-кәрзиннең тоткасын ясау өчен тимер чыбыкны алабыз һәм лента белән әйләндерәбез. **(9слайд)**

-кәрзиннең тоткасы әзер (**10слайд**)

-кәрзиннең тоткасын инәләр белән беркетеп куябыз. (**11слайд**)

**Менә безнең кәрзинебез әзер. (11слайд)**

**Чәчәкләр ясыйбыз.**

**-моның** өчен лентаны инәләргә кертеп барабыз. **(12слайд)**

-4 чәчәккә яфрак ясыйбыз, яфрак ясау өчендә лентаны инәгә кертәбез һәм чәчәкне кәрзингә беркетәбез. **(13слайд)**

-ясап беткән чәчәкләрне кәрзингә беркетеп барабыз. **(14слайд)**

**Менә безнең “Кәрзиндә чәчәкләребез” әзер. (15слайд)**